**Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы**
**Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәр Советы**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре № 54-11 «26» октябрь 2021 ел

Азнакай муниципаль районы Советының 2017 елның 13 декабрендәге 77-20 номерлы «Азнакай муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районы рәсми сайтында һәм әлеге белешмәләрне бастырып чыгару өчен гомумроссия массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибе турында» карары белән расланган, Азнакай муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне Азнакай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру тәртибенә үзгәреш кертү һәм әлеге белешмәләрне бастырып чыгару өчен бөтенроссия массакүләм мәгълүмат чараларына бирү турында (2018 елның 30 мартындагы 89-24 нче номерлы, 2021 елның 25 июнендәге 39-9 нчы №39-9 номерлы карарлар редакциясендә)

Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 10 декабрендәге 778 номерлы «Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында» Указын үтәү йөзеннән,

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәр Советы

**карар итте:**

1. Азнакай муниципаль районы Советының 2017 елның 13 декабрендәге 77-20 номерлы «Азнакай муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районы рәсми сайтында һәм әлеге белешмәләрне бастырып чыгару өчен гомумроссия массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибе турында» карары белән расланган, Азнакай муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне Азнакай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру тәртибенә үзгәреш кертү һәм әлеге белешмәләрне бастырып чыгару өчен бөтенроссия массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибенә (2018 елның 30 мартындагы 89-24 нче номерлы, 2021 елның 25 июнендәге 39-9 нчы №39-9 номерлы карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның г) пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«г) җир кишәрлеген, күчемсез мөлкәтнең башка объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләрне (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлеше, пайлар, цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу буенча алыш-бирешләрнең гомуми суммасы (мондый алыш-биреш суммасы) муниципаль вазыйфаны биләп торучы затның һәм аның хатынының (иренең) соңгы өч елда гомуми кеременнән артса, акча алу чыганаклары турында белешмәләр.».

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М. З. Шәйдуллин